**ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422701, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Высокая Гора, ул.Юбилейная, 1а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Юбилей ур, 1а

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79, e-mail: VgorVsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

09 сентября 2021 г. | № 119

**Пермяк авыл җирлеге Советы карарларын гамәлдән чыгару турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына узгәрешләр кертү турында» 2013 елның 20 маендагы 42-ЗРТ Татарстан Республикасы Законына, Биектау муниципаль районы «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛА:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Пермяк авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

- 2009 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы «Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында»;
- 2009 елның 30 гыйнварындагы 2 номерлы «Пермяк авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматлары белән эшләү турындагы нигезләмәне раслау хакында»;
- 2009 елның 19 июнендәге 14 номерлы «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттереп алу һәм юкка чыгару тәртибе турында»;
- 2009 елның 28 июлендәге 21 нче номерлы «Пермяк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»;
- 2009 елның 1 октябрендәге 24 номерлы «Пермяк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»;
- 2009 елның 1 октябрендәге 25 номерлы «Пермяк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрендә халыкның тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү турындагы нигезләмәне раслау хакында»;

- 2010 елның 25 июнендәге 21 номерлы «Пермяк авыл җирлеге су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү һәм һәлак булуын булдырмау чаралары турында»;

- 2010 елның 31 августындагы 33 номерлы «Пермяк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен һөнәри яңадан әзерләүгә, квалификацияләрен күтәрүгә һәм стажировкасына муниципаль заказ турында»;

- 2010 елның 20 сентябрендәге 34 номерлы «Энергияне саклау буенча закон бозуларны бетерү турында»;

- 2010 елның 20 сентябрендәге 35 номерлы «Пермяк авыл җирлегенең ревизия комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында»;

- 2010 елның 15 октябрендәге 3 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»;

- 2010 елның 15 октябрендәге 4 номерлы «Җир салымы турында»;

- 2010 елның 30 декабрендәге 19 номерлы «Пермяк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»;

- 2011 елның 22 февралендәге 21 номерлы «Биектау муниципаль районының Пермяк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәттә үз-үзеңне тоту кодексын раслау турында»;

- 2011 елның 14 апрелендәге 25-1 номерлы «2011-2012 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Пермяк авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә «муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында»;

- 2011 елның 4 маендагы 33 номерлы «Биектау муниципаль районының Пермяк авыл җирлеге муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында»гы Нигезләмәне раслау хакында»;

- 2011 елның 18 июлендәге 49 номерлы «Пермяк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны җайга салу турында»;

- 2012 елның 23 мартындагы 78 номерлы «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында»;

- 2012 елның 23 маендагы 88 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Пермяк авыл җирлеге Советының 2010 елның 15 октябрендәге «җир салымы турында " гы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»;

- 2013 елның 20 февралендәге 121 номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар тирәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү турында».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз өстемә алам.

**Совет рәисе,**
**Биектау авыл җирлеге Башлыгы Ю.М.Галимов**